АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423740,село Актаныш, Проспект Ленина,дом 58.Тел.3-44-40

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт. Тел.3-44-40

**КАРАР**

№ 3 «18» гыйнвар 2021 ел

**2021 елга хатын-кызлар советының эш планын раслау турында**

Хокук саклау органнарына һәм башка дәүләт органнарына хокук тәртибен тәэмин итүдә ярдәм итү, социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүгә киң җәмәгатьчелекне җәлеп итү, хатын-кызларның, гаиләнең, ананың һәм балачакның хәлен яхшырту, хатын-кызларның җәмәгать эшләрендә актив катнашуы өчен иң уңай шартлар тудыру максатыннан чыгып Актаныш авыл башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге территориясендә 2021 елга хатын-кызлар советының чаралар планын расларга (№1 кушымта).
2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Актаныш авыл җирлеге бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Актаныш авыл Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Шарипов

Актаныш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе
18.01.2021 ел № 3 карарына
кушымта

Актаныш авыл җирлеге хатын-кызлар Советының 2021 нче елга эш планы

| № п/п | Чара | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| | **Оештыру чаралары** | | |
| 1 | Актаныш авыл җирлеге каршындагы хатын-кызлар Советының 2021 елга эш планын раслау | январь | Совет рәисе, сәркатибе |
| 2 | Совет утырышларын үткәрү (Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районындагы бүлеге беркетмәләре һәм тәкъдимнәре буенча материалларны карау һәм тикшерү, белем бирү учреждениеләре тәкъдимнәре һәм үтенечнамәләре, гражданнарның авыл җирлеге гражданнарына карата шикаятьләре һ. б.), түгәрәк өстәлләр | Кварталга 1 тапкыр | Совет әгъзалары |
| 3 | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләре белән берлектә эшсез хатын-кызларны, инвалидларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге турындагы сорауларны шәхси тәртиптә карап тикшерү | Кварталга 1 тапкыр | Совет әгъзалары |
| 4 | Район хатын-кызлар советы утырышларында һәм чараларында, Актаныш авыл җирлеге башкарма комитетының гомуми җыелышларында катнашу | Ел дәвамында | Совет әгъзалары |
| 5 | Җәмгыятьнең аерым игътибарына мохтаҗ хатын-кызлар һәм гаиләләр (күп балалы, ялгыз аналар, ялгыз өлкән яшьтәге, социаль куркыныч хәлдә калган һ. б.) белән эшне оештыру | ел дәвамында | Совет әгъзалары |
| 6 | Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча өмәләрдә/икеайлыкта катнашырга | Апрель-сентябрь | Совет әгъзалары |
| 7 | Хатын-кызлар советы эшчәнлегенә анализ ясарга, нәтиҗәләр буенча аны камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр эшләргә | елга 1 тапкыр | Совет әгъзалары |
| | **Гомумпрофилактик чаралар** | | |
| 1 | Полиция участок вәкилләре белән берлектә имин булмаган социаль төркемдәге гаиләләрнең яшәү урыны буенча рейдлар оештырырга:<br>-хәмердән явызларча файдаланучы гаиләләр;<br>-балигъ булмаган хокук бозучылар һ. б. категорияләр | ел дәвамында | Совет әгъзалары |
| 2 | Социаль куркыныч хәлдә булган, имин булмаган гаиләләрне ачыклау буенча рейд чараларында катнашу. Әлеге гражданнар белән индивидуаль-профилактик эш алып бару | ел дәвамында | Совет әгъзалары |
| 3 | Эчкечелекне(наркомания, тәмәке тартуны) һәм башка хокук бозуларны кисәтү максатыннан | ел дәвамында | Совет әгъзалары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча булеге, Актаныш авыл җирлегендә балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе белән берлектә яшьләр (яшүсмерләр)күплэп урнашу урыннарын тикшерү буенча рейд чараларында катнашу | | |
| 4 | Алкогольле һәм ялган алкогольле продукцияне законсыз сату урыннарын ачыклау буенча рейд чараларында катнашу | ел дәвамында | Совет әгъзалары |
| | Хатын-кызлар Советы утырышлары | | |
| 1 | Авыл җирлеге Хатын-кызлар Советынын 2021 елга бурычлары, эш планын раслау турында | январь | Совет әгъзалары |
| 2 | Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруга багышланган район чарасында катнашу турында | февраль | Совет әгъзалары |
| 3 | Җирлекнең социаль паспортын төзүдә катнашу | ел дәвамында | Совет әгъзалары |
| 4 | Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган чараларда катнашу турында | март | Совет әгъзалары |
| 5 | 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүне бәйрәм итүдә катнашу турында | май | Совет әгъзалары |
| 6 | Халыкара гаилә көнен, Халыкара балаларны яклау көнен үткәрүдә катнашу турында | Май-июнь | Совет әгъзалары |
| 7 | ГХАТ бүлеге тарафыннан гаилә тормышы юбилярларына багышланган чараларда катнашу (55,60 ел) турында | ел дәвамында | Совет әгъзалары, Башкарма комитетнын ГХАТ булеге |
| 8 | «Мәктәпкә җыенырга булыш» акциясендә катнашу турында | август | Совет әгъзалары, социаль яклау булеге |
| 9 | Район спартакиадасында һәм Өлкәннәр көненә багышланган чараларда катнашу турында | октябрь | Совет әгъзалары, яшьләр, спорт хэм туризм булеге |
| 10 | Аналар көненә багышланган район чарасында катнашу турында | ноябрь | Совет әгъзалары, социаль яклау булеге |
| 11 | Район спартакиадасында, «Игелек марафоны» хәйрия акциясендә һәм инвалидлар декадасына багышланган башка чараларда катнашу турында | декабрь | Совет әгъзалары, социаль яклау булеге |
| 12 | 2021 елга хатын-кызлар Советы эшенә йомгак ясау, 2022 елга эш планы проектын эшләү | декабрь | Совет әгъзалары |